МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.09.2015 г.Казань № 223/2-пр

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2014-2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы турында” 2013 елның 12 октябрендәге 922 номерлы карарын үтәү максатында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

“1.12. “Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә “2014-2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча мелиорация эшләрен үткәрүгә 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе (12 нче кушымта)”;

2. Боерыкка 12 нче кушымтаны әлеге Боерыкка 1 нче кушымтада бирелгән редакциядә бәян итәргә.

3. Боерыкка 7 нче кушымтаның 10 пунктындагы унынчы, унберенче, уникенче абзацларын төшереп калдырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2015 елның 25 сентябрендәге 223-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
боерыгына
1 нче кушымта

2015 елның 15 гыйнварындагы 3-2/пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
боерыгына
12 нче кушымта

# Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә "2014-2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү" федераль максатчан программасы буенча мелиорация эшләрен үткәрүгә 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына "2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү" федераль максатчан программасы буенча (алга таба – Программа) мелиорация эшләрен үткәрүгә 2015 елда субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү тәртибе механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирүнең максатлары климат үзгәрү һәм табигать аномалияләре шартларында комплекслы мелиорация чаралары ярдәмендә авыл хуҗалыгы җитештерүенең продуктивлыгын һәм тотрыклылыгын, шулай ук туфракның уңдырышлылыгын арттырудан, мелиорация үткәрелә торган җирләрнең продуктив потенциалын һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны арттырудан гыйбарәт.

3. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр аларның төп эшчәнлек торе үсемлекчелек продукциясен җитештерү булса гына бирелә.

Субсидияләр гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы су белән тәэмин итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазлау буенча проект һәм тикшеренү эшләрен башкаруга һәм (яки) проект документациясен әзерләүгә бирелә алмый.

4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр түбәндәгеләргә бирелә:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең милке булган яки аларга билгеләнгән тәртиптә файдалануга тапшырылган гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы мелиорация системаларын һәм аерым урнашкан гидротехник корылмаларны (алга таба – объектлар) төзү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазлау чыгымнарының бер өлешен каплауга;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең милке булган (аларга арендага тапшырылган) гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы сугару һәм киптерү системаларын инновацияле технологик нигездә төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазлау, төзелешнең җыелма смета исәп-хисабы бәясенә кертелгән (шул исәптән лизингка сатып алынган һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең баланс исәбенә куелган) машиналарны, җайланмаларны, яңгыр кебек яудыру һәм су сибү аппаратларын, насос станцияләрен сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга, моңа Татарстан Республикасы хуҗалыкларының һәм муниципаль районнарының күрсәтелгән объектлар буенча проект һәм тикшеренү эшләрен башкаруга һәм (яки) проект документациясен

әзерләүгә бәйле чыгымнары керми. Субсидияләрнең күләме Программага кертелгән объектларны төзи башлаганнан алып башкарылган эшләр күләменең иң күбе 50 проценты исәбеннән чыгып билгеләнә.

5. Субсидияләрне алу өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) түбәндәге документларны тапшыралар:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

объектларны төзүгә, реконструкцияләүгә, торгызуга җыелма смета исәп-хисапларының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

эшләр башкаруга подряд шартнамәләрен;

КС-2 статистика формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында актны;

объект төзелә башланганнан алып КС-3 статистика формасы буенча башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында белешмәне;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләрен.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан таныклана.

Субсидияләр бирүнең өстәмә шартлары түбәндәгеләр: сугарыла торган участокны яки гидротехник корылманы мелиорация җиһазларының тәкъдим ителгән техник характеристикалары һәм сугару системасының аерым өлешләренең урнашу схемалары буенча төзү яисә торгызуның мөмкин булуы турында техник күзәтчелекне гамәлгә ашыручы органның бәяләмәсе булу.

Техник күзәтчелекне (төзелеш контролен) гамәлгә ашыручы орган – ул “Татарстан Республикасы буенча Җирләр мелиорациясе һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе” федераль дәүләт бюджет учреждениесе.

Заказчы һәм техник күзәтчелек (төзелеш контроле) хезмәтен тоту чыгымнарын финанслау Программаны бюджеттан финанслау суммасының 2,14 проценты күләмендә федераль бюджеттан башкарыла.

6. Министрлык:

субсидияләр бирү соралган гаризаны кергән көнендә үк журналга терки, ул номерлана, шнурлана һәм аңа мөһер сугыла;

әлеге Тәртипнең 5 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый. Документларны карау срогы гариза теркәлгән көннән алып 5 эш көненнән күбрәк булырга тиеш түгел.

Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

документларның тулы булмаган комплекты тапшырылу;

бюджет йөкләмәләре лимитлары калмау.

Субсидияләр бирүдән баш тартылуга шикаять Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә агымдагы ел дәвамында бирелә.

7. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны, Министрлык тарафыннан расланган субсидияләр бирү өчен җыелма исәп-хисап белешмәләренә нигезләнеп, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган хосусый счетыннан

Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына әлеге Тәртипнең 10 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән срок беткәннән соң 2 эш көне эчендә күчерә.

8. Алынган субсидияләр, аларны бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап 60 көн эчендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

9. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты кеременә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

10. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет кеременә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

11. Министрлык һәм (яки) дәүләт финанс контроле органы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

12. Тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык авыл хуҗалыгы товарларын җитештереүчеләргә һәм Министрлыкның муниципаль районнардагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыкларына йөкләнә. Хокук бозучыларга карата законнарда билгеләнгән җаваплылык чаралары кулланыла.

13. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.